МБОУ Среднетиганская СОШ
Алексеевского муниципального района
Республики Татарстан

# Проект по направлению «Социальная защита и волонтёрская деятельность»

## по теме «По зову сердца»



**Работу выполнили: ученики 7 класса МБОУ Среднетиганской СОШ**

**Алексеевского муниципального района Республики Татарстан**

**Руководители проекта: классный руководитель Баязитова Э.А.**

**и родители учащихся 7 класса МБОУ Среднетиганской СОШ**

**Алексеевского муниципального района Республики Татарстан**

**Эпиграф**

Сегодня праздник на нашей Земле —
Знаком он, сегодня, любой детворе,
И каждый спешит поздравить своих:
Бабушек, дедушек — самых родных!

**Введение.**

Международный день пожилых людей - это особый день для старших граждан по всему миру. Сегодня во всем мире насчитывается около 600 млн. человек, возраст которых составляет 60 лет и более. В нашем быстро стареющем мире «ветераны жизни» всё чаще будут играть решающую роль – передавая накопленный опыт и знания, помогая своим семьям. Уже сейчас пожилые люди вносят существенный вклад в развитие общества. Зрелые люди - это новая сила для развития.

**Актуальность**

Уходя на пенсию, пожилые люди нуждаются не только во внимании, связанном в организации их быта. Особый смысл для этих людей приобретают формы духовного общения с детьми, когда они поздравляют их с праздниками, рассказывают о своих делах. Это пробуждает в пожилом человеке жажду к жизни, понимания своего места в обществе. Для детей - это приобретение духовно-нравственных ценностей. У детей, заботящихся о пожилом человеке, навсегда заложится в душе понимание к нуждам стариков и потребность в оказании помощи этим людям. В наше время, когда человек в погоне за карьерой, за деньгами забывает о главных человеческих ценностях, важно напоминать о них.

**Цели проекта:**

- укрепление связи между поколениями,
- привлечение внимания к проблемам людей пожилого возраста,
- пропаганда общения с людьми преклонного возраста

**Задачи:**

- формирование коммуникативной компетентности в сотрудничестве (умение вести диалог, участвовать в совместной деятельности с учащимися класса, родителями; способности доброжелательно и чутко относиться к людям, сопереживать)
- формировать уважительное отношение к старшему поколению,
- развивать артистичность выразительность исполнения стихотворений, песен.

**Направления проекта**:

I. Помощь, доброе дело, понимание, сострадание, уважение по отношению к:

1) Ближнему (родителям, дедушкам и бабушкам)

2) Пожилым людям – соседям, односельчанам.

**Основополагающий вопрос**: Какова ответственность подрастающего поколения перед людьми преклонного возраста.

**Проблемные вопросы**:

- Как можно бескорыстно оказывать помощь?
- Легко ли быть милосердным?
- Что должны сделать мы, чтобы милосердие не исчезло из нашей жизни?

**Учебные вопросы**:

- День пожилого человека – официальный праздник в России
- Что думают о жизни людей преклонного возраста родители, близкие, друзья?
- Каково отношение к ним государства?

**Ожидаемые результаты**:

1. Изучение истории праздника «Дня пожилого человека».

2. Формирование гражданских и патриотических чувств, любви и сострадания к ближнему.

3. Способствовать развитию у учащихся навыков познавательной, творческой деятельности

4. Пропаганда общения с людьми преклонного возраста (близкими, соседями, ветеранами)

**Вид исследовательской работы**

Социальный проект, краткосрочный

**Оборудование:** ноутбук, проектор, плакаты.

**Организаторы проекта:** учащиеся и родители 7 класса, классный руководитель Баязитова Э.А.

**Партнеры проекта:** родители, бабушки и дедушки учеников, пожилые люди села, ветераны ВОВ.

**Сроки реализации проекта**: сентябрь 2018 г. – октябрь 2018 г.

**План работы.**

| № | Наши дела | Сроки | ответственные |
|---|---|---|---|
| 1. | **Подготовительный**<br>Обсуждение плана. Найти материал об истории праздника. | 20.09.18г. | Ученики 7 класса, классный руководитель. |
| 2. | **Организационный**<br>Найти поздравительные стихи.<br>Придумать концертные номера. | 24.09.18г. | Родители учащихся 7 класса |
| 3. | **Практический**<br>Оформление афишки. Изготовление открыток, поздравительных плакатов. | 25.09.18 - 29.09.18 г | Ученики и родители 7 класса, |
| | Репетиция танцев, песен, стихотворений. | 25.09.18 - 29.09.18 г | Ученики 7 класса, классный руководитель, родительский комитет класса. |
| 4. | **Заключительный.**<br>1.Поздравить с праздником ветеранов ВОВ.<br>2. Концерт для пожилых людей в сельском доме культуры.<br>3.Концерт для бабушек и дедушек в классе. Чаепитие. | 29.09.18 г | Ученики 7 класса, классный руководитель, родители учащихся. |
| 5. | **Обсуждение о проделанной работе.** | 29.09.18 г-1.10.2018г. | Ученики 7 класса, классный руководитель, родители учащихся. |

**I  Этап – Подготовительный**




**Мой самый дружный и активный класс!**



**Беседа о празднике.**

***Родители учащихся:***

Это особенный праздник, день уважения и почитания пожилого человека. Этот праздник возник в XX веке. Сначала День пожилых людей начали отмечать в Европе, затем в Америке, а в конце 80-х годов во всем мире.

**14 декабря 1990 года** Генеральная Ассамблея ООН постановила считать **1 октября** Международным днём пожилых людей, а в Российской Федерации этот праздник отмечается с 1992 года. С тех пор ежегодно, в золотую осеннюю пору мы чествуем тех,

кто все свои силы и знания посвятил своему народу, кто отдал здоровье и молодость молодому поколению. Празднование этого дня - знак признания демографического вступления человечества в пору зрелости и тех перспектив, которые оно раскрывает для развития более полных представлений и возможностей в общественной , экономической, культурной и духовной жизни пожилых граждан. Учреждение такого дня и празднование его в России - это вековая дань традициям уважения и почитания старости, это знак общественного признания огромного вклада пожилых людей в формирование экономического и духовного потенциала общества, многогранного вклада в развитие государства. В соответствии с классификацией Всемирной организации здравоохранения к пожилому относится население в возрасте от 60 до 74 лет, к старому - от 75 до 89 лет, к долгожителям- 90 лет и старше. Рубеж 65-летнего возраста нередко выделяется особо, так как во многих странах этот возраст сопряжен с выходом на пенсию. Новый социальный статус человека в старости, вызванный прежде всего прекращением или ограничением трудовой деятельности, изменениями самого образа жизни и общения, трудностями адаптации к новым условиям, требует особых подходов, форм и методов работы с пожилыми людьми. Ежегодное проведение Дня пожилого человека в России становится важным инструментом для улучшения положения граждан старшего поколения нашей страны, нуждающихся в особой защите государства.

(**В приложении 1** – сценарий мероприятия, составленный родителями учащихся)

## II. Этап – Организационный:

Ищем стихотворения для поздравления:

А мы пойдем и будем дарить бабушкам и дедушкам открытки, которые ребята сделали, и поздравлять будем стихами.



## III Этап - Практический



Оформление афишки. Изготовление открыток, поздравительных плакатов.





Репетиция танцев, песен, стихотворений.

Стихи дети читают при поздравлении. (Приложение 1)

**IV этап – Заключительный:**

**Изготовлены афишки и вывешены:**







Поздравили с праздником ветеранов ВОВ:



Концерт для пожилых людей в сельском доме культуры.



**Концерт для бабушек в классе.**









**Чаепитие**



**V этап – Обсуждение о проделанной работе.**

**Приложение 1**

**Сценарий внеклассного мероприятия для пожилых людей.**

# Ягез әле, әбиләр һәм оныклар!

Зал бәйрәмчә бизәлгән.

**Максат:**
Укучыларда, халык традицияләренә нигезләнеп, әти-әниләргә, әби-бабайларга, туганнарга, якын кешеләргә карата хөрмәт, ихтирам хисләре тәрбияләүгә ярдәм итү.

**Бурычлар:**
-туганнарны хөрмәт итәргә, олыны олыларга, кечеләргә ярдәм итәргә өйрәтү.
- жырлы – биюле уеннарга кызыксыну уяту.
-балаларның уйлау фикерләү сәләтен үстерү, зирәклек, тапкырлык, игътибарлылык, күзәтүчәнлек тәрбияләү.
- әби-бабайларны хөрмәтләргә, аларның кайгыртучанлыгын аңларга, тыңлаучан булырга өйрәтү.

**Җиһазлар:** чигелгән солгеләр, презентация, ноутбук, яулык, түбәтәй, бию очен татар халык костюмнары.

Әбиебез, кадерлебез безнең,
Иң өлкәне шушы гаиләдә.
Чын йөрәктән сине котлар өчен
Җыелыштык бүген бәйрәмгә.

Әлегәчә ару белмәс үзең,
Куандыра татлы ризыгың.
Кышын һәрберебез аягында
Була синең мамык оегың.

Рәхмәт, әби, сине күрү шатлык,
Беркайчан да авыру белмә син!
Саф күңел ул картаюны тоймый,
Йөзләреңне кояш бизәсен!

Эзләсәң дә табып булмый
Сезнең кебек изге җаннарны.
Кулдан килсә, бүләк итәр идек,
һавадагы йолдыз — айларны.

**Самат Камалов:** Хәерле көн, кадерле килгән кунаклар, зур энилэр!
Илебез буенча октябрь ае башында Өлкәннәр көне уздырыла. Төрле җирләрдә өлкәннәрне котлаулар, бүләкләүләр, искә алулар бара.
Өлкән кешеләр – безнең эти-әниләребез, әби-бабайларыбыз. Алар бик күп авырлыклар күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган кешеләр. Аларны өлкән булган өчен генә түгел, ә эти-әниләребез, әби-бабайларыбыз булган өчен дә хөрмәт итәргә тиешбез.

Бүген сезгә сәлам юллыйбыз без,
Сәлам сезгә безнең буыннан!
Бар дөньяны бүләк итәр идем
Әгәр килсә минем кулымнан!

**Укытучы сойли:** Хөрмәтле әбиләребез! Дәү әниләребез! Сез – тыйнак та, сөйкемле дә, сез – эшчән дә, түземле дә, сез – иманлы да, дәрманлы да. Сез өйләребезнең яме, ашларыбызның тәме. Дөнья йөген сез күтәргәнсез, гаилә учагын сүндермичә, сүрелдермичә, сез дөрләтеп торасыз.
Саф күңелле булып калганыгыз өчен, яхшы ул-кызлар тәрбияләп үстергәнегез, ә хәзер инде онykларыгызны тәрбияләгән өчен рәхмәт сезгә! Озын гомер, сәламәтлек телибез сезгә, әбиләр! Оныкларыгызның игелеген күрегез!

Күбәләктәй оча яшьлек
Талпына, канатлана.
Өлкәннәрдән үткән ялкын
Яшьләрдә кабатлана.
Аякларга күз иярми
Алар җиргә тимиләр,
Безнең балалар әнә ничек
Очкын чәчеп бииләр.

Уйныйк әле, җырлыйк әле
Биик әле күп итеп.
Безнең бәйрәм кичәбезне
Сагнып сөйләрлек итеп

*Бию (заманча)*

**Ильсинә Хисмиева:**
Кем дөньяга кеше бүләк итә?
Ә кешегә якты дөньяны
Тойгылары кояш кебек кайнар
Эретерлек гранит кояны.
Кем күңеле тулган айдай серле,
Язлар сыман назлы, ягымлы.
Шатлыкларын башкаларга бүлә
Кайгыларга түзем, сабырлы.
Кем елмая җәйге таң аткандай
Балкып китә шундук тирә-як.
Нәфислеге гөлләр сокланырлык
Көләчлектә аңа тиңнәр юк.

Кем куллары өйне, җирне ямьли,
Изгелеге үлчәү тапкысыз.
Ул әлбәттә яшәү чыганагы,
Тормыш яме - әнкәй, әбекәй, хатын-кыз!

**Алып баручы:** *Сезнең өчен җыр. (Башкаралар 7 нче сыйныф укучылары)*

Айдар Юнысов көе һәм сүзләре

**"Рәхмәт Әни, Әти"**

Бу дөньялар бер тик тормый,
Була кайгы, шатлыклар.
Авыр чакта Әти, Әни
Җил-давылдан ышыклар.

Кушымта:
Рәхмәт Әни, рәхмәт Әти,
Гомерне биргән өчен.
Йөрәктәге бар җылыны
Сакларбыз Сезнең өчен!
...
Сезнең йөзләрне күрергә
Һәр көнне сагынып кайтам.
Әти-Әни, бу җырымда
Рәхмәтләр Сезгә әйтәм!
...
Сезнең киңәшләрсез бармый
Минем һәрбер эшләрем.
Әти-Әни - иң кадерле,
Иң изге кешеләрем!!

**Алып баручы:** Бөтен кешелек дөньясына ямь бирүче, елмаюыгыз белән безне иркәләүче, җылы карашларыгыз белән назлаучы, акыллы фикерләрегез белән безгә ак юл күрсәтүче сөекле әбиләребез, дәү әниләребез!

Әбиләр көне бүген булса да
Күңелегез сезнең гел яшь.
Торсагыз иде безнең арада
Булып назлаучы кояш.

**Самат Камалов:**
Кояш көлеп уянды ды
Нурларын сипте мулдан.
Әбиләр килде мәктәпкә
Атлап кояшлы юлдан.
Һәр җирдә бер хикмәт көтә
Бүген гади көн түгел.

Бүген - Әбиләр бәйрәме
Шуңа шатлана күңел.
Нинди назлы, нинди эшчән
Синең куллар әбием!
Бөтен дөнья бәйрәм итә
Сезне зурлап әбием!

**Данис Зарипов:** Гомерләре буе хезмәттә кайнаган, сугыш һәм сугыштан соңгы авырлыкларны иңнәрендә күтәргән, колхоз нужасын беренче көннәреннән үк тәртәгә җигелеп тарткан әби-бабаларыбыз картлык көннәрендә зур игътибарга, хөрмәткә лаек.
Рәхмәт сезгә, бу дөньяда куйган хезмәтләрегез, кылган изгелекләрегез өчен. Без, яшьләр, сезнең киңәшләрегездән тайпылмабыз, үрнәк булырга тырышырбыз.

*Сезнен очен "Урак белэн бию" (Башкаралар 7 нче сыйныф укучылары)*

**Камиль Сахабутдинов:**
Кадерле әбиләребез,
Чал чәчле дәү әниләребез!
Бәйрәм белән котлыйм бүген
Сезне ул һәм кызларыгыз.
Яшәгез сез мәңге яшь булып,
Туган йортыгызда ямь булып.
Сез булсагыз таза-сәламәт
Оныкларга булыр бик рәхәт.

**Данис Зарипов:** Әбием! Нинди ягымлы, нинди җылы сүз! Аны әйтү белән күз алдыбызга мөлаем бер илаһи зат килеп баса. Яше сиксәнгә җитсә дә, илледә генә булса да, ул – безнең өчен изгелек чыганагы. Гомернең сикәлтәле еллары артта калды. Маңгайларга сырлар төшкән, чәчләргә кырау кунган. Күңелегезгә тормышның барлык хатирәләре сыйган. Ә киләчәккә ышаныч барыбер сүнмәгән. Тормыш авырлыклары да бу ышанычны сүндерә алмаган. Ак яулыклы татар әбисе!

**Дильшат Давлетшин:**
Оныкларга терәк булып,
Яшәгез сез шатлыкта.
Сәламәтлек, ак бәхетләр
Юлдаш булсын картлыкта.
Картаймыйча шулай кояш кебек
Балкып торыгыз сез иртә-кич
Яхшылыкны җирдә ятмый диләр
Онытмабез сезне без һич тә.

**Рэмилә Зарипова:**
Минем әбием бик уңган
Бар эшкә дә өлгерә.
Юа, җыя, тегә, бәйли,
Тәмле ашлар пешерә.
Тор бәбкәм, уян дип,
Дәү әнием уята.

Көләч йөзле әбиемне
Һәммәбез дә ярата.
Өйгә кайтсам, өй балкыган,
Өйгә нур иңгән.
Ерак җирне якын итеп
Әбием килгән.
Ышаныгыз, без мәктәптә
Бик тырышып укырбыз.
Кайгы-хәсрәтләр китерми
Таянычыгыз булырбыз.

**Ильсинә Хисмиева:**
Сандугачның балалары
Талга кунганнар икән;
Кара, болар чәчрәп тора,
Бигрәк уңганнар икән
Җилсез орчык эрлисең,
Әрле-бирле йөрисең;
Бигрәк оста биисең,
Күз тияр дип белмисең

*Татар биюе (Башкаралар 7 нче сыйныф укучылары)*

**Самат Рахматуллин:**
Әбиләргә бурычлы без,
Рәхмәтле без мең тапкыр.
Әгәр берәр эшең булса,
Әбием, безне чакыр.
Әби кеше гел яхшылык тели,
Гаебебез булса кичерә.
Гомер буе калыйк тугрылыкта
Әби дигән изге кешегә.

**Зилә Валиева:**
Кичләрен иркәләп мине,
Җырлый-җырлый йоклаткан.
Аның ягымлы көлүе
Кайгыларны тараткан.
Әбиемнең җылы кулы
Чәчләремен сыйпады.
Бүгенге матур бәйрәмдә
Тәбриклибез без аны.
Әбиләр – мәңгелек шатлык,
Язгы шатлык, язгы нур.
Әбиләргә багышлана
Дөньяда иң назлы җыр.

Бүген сөенә-сөенә
Шушы җырны җырлыйбыз.

Сезне, кадерле әбиләр,
Бәйрәм белән котлыйбыз.

**Җыр.”Ак яулыклы эбием”.** *(Башкаралар 7 нче сыйныф укучылары)*
Г.Зарипова музыкасы, М. Рахмаев сүзләре.

1.Ак яулыклы, йөзе нурлы
Жылы куллы эбием
Балачактан угет биргән
Сердәшчем син, кадерлем

Чәчләренә чал керсә дә
Булдын син бик яшь
Авыр чакларда кызым дип
Бирден син киңәш

2.Озын юлларга чыкканда
Ташламадын доганнан
Озын гомер булсын диеп
Гел сорыйм мин Ходайдан

Чәчләренә чал керсә дә
Булдын син бик яшь
Авыр чакларда кызым дип
Бирден син киңәш

**Данис Зарипов:**
Әй сез, татар әбиләре,
Нур сибә йөзләрегез.
Шуңа күрә дә яз сыман
Сезнең чал йөзләрегез.
Чәчләргә ак карлар яусалар да,

Язлар яши сезнең күңелдә.
Өйрәнсеннәр яшьләр, сезгә карап,
Сокланырлык тормыш төзергә.

Бәхетләре булсын җирдә һәр кешенең
Күге аяз, җире гел чәчәк.
Һәммәбезгә - сезгә, безгә, илгә
Без телибез якты киләчәк

**Бүләкләр өләшенә.**